КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«03»07.2019г. № 49-п

2019 елда коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” республика конкурсы үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган “2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасы коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру турында” дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында, боерык бирәм:

1. Коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” республика конкурсын оештырырга һәм үткәрергә.

2. 2019 елда коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” республика конкурсын үткәрү турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

3. Әлеге боерык басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары И.Ф. Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче А.Р.Зарипов

“Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2019 елның 3нче июлендә 49-п номерлы боерыгы белән РАСЛАНДЫ

**2019 елда коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” республика конкурсы үткәрү турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” республика конкурсы (алга таба – Конкурс) “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Оештыручы) тарафыннан “Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында” 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган “2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасы коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру турында” дәүләт программасы (алга таба – Программа) нигезендә үткәрелә.

1.2. Конкурсны оештыручы/гамәлгә куючы – “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык);

1.3. Конкурс үткәрү турында хәбәр Агентлыкның рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар”, “Конкурслар” бүлекләрендә урнаштырыла.

1.1. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм акчалата бүләкләр тапшырыла;

1.2. Конкурска бер генә гариза керсә һәм/яисә бер гариза да кермәсә, Конкурс үткәрелмәде дип таныла.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты – массакүләм мәгълүмат чаралары һәм җәмәгатьчелек игътибарын коррупция мәсьәләләренә җәлеп итү.

2.2. Конкурсның төп бурычлары:

- коррупция мәсьәләләрен массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны стимуллаштыру;

- коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләрен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту;

- халыкка коррупция чагылышларына бәйле хәлләрнең тискәре нәтиҗәләре турында аңлату;

- коррупция чагылышларына бәйле хокук бозуларны профилактикалау буенча актив гражданлык позициясе булдыру;

- гражданнарда коррупциягә каршы һәм хокукый караш тәрбияләү;

- тәрбияви һәм иҗтимагый кыйммәтләр, халыкта коррупциягә каршы гамәлгә ашырыла торган программаларның язмышы өчен җаваплылык хисе тәрбияләү, хакимияткә ышанычны ныгыту.

## 3. Конкурсның өстенлекле юнәлешләре (темалары)

3.1. Конкурста катнашу өчен массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләреннән һәм авторларыннан Конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килә торган түбәндәге өстенлекле юнәлешләр (темалар) буенча басылып чыккан (эфирда дөнья күргән) эшләр кабул ителә:

- халыкның хокукый гыйлемен арттыру, халыкка коррупция күренешләренең булырга мөмкин рәвешләре һәм аларга каршы тору турында мәгълүмат бирү;

- тормышның төрле өлкәләрендә физик затның вазыйфасыннан, вәкаләтләреннән явыз ниятләрдә файдалануына, бюджет чараларын максатсыз тотуга, шулай ук ришвәтчелеккә (коммерциячел сатып алуга) бәйле хокук бозуларны яктырту;

- хокук саклау органнарының коррупциячел күренешләр һәм алар аркасында барлыкка килгән куркыныч хәлләргә каршы эшчәнлеген яктырту;

- дәүләт хакимияте органнары эшчәнлегендә һәм бизнеста ачыклыкка ирешүгә ярдәм итү, дәүләт хакимияте органнарының, иҗтимагый оешмаларның һәм башка структураларның коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру эшчәнлеген яктырту һәм коррупциягә каршы көрәшнең үтемлелеген арттыру;

- төрле төбәкләрдә, шул исәптән чит илләрдә коррупциягә каршы көрәшнең уңай тәҗрибәсен һәм нәтиҗәле ысулларын яктырту;

- коррупция чагылышларын өйрәнү өчен социологик һәм башка тикшеренүләр, коррупциягә каршы көрәшнең проблемалы мәсьәләләре турында фикер алышу өчен дискуссия мәйданчыклары.

## 4. Конкурсның номинацияләре

Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

- “Вакытлы матбугат басмаларында коррупциягә каршы иң яхшы язмалар сериясе”;

- “Коррупциягә каршы иң яхшы телесюжетлар сериясе”;
- “Коррупциягә каршы иң яхшы радиосюжетлар сериясе”;
- “Интернет басмаларда коррупциягә каршы иң яхшы язмалар сериясе”.

Күрсәтелгән номинацияләрдә 1, 2, 3 урыннар алган җиңүчеләр билгеләнә.

Махсус номинация:

- “Коррупциягә каршы иң яхшы журналист тикшеренүе”.

Махсус номинациядә бер генә җиңүче билгеләнә.

## 5. Конкурста катнашучылар

5.1. Конкурста массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, аерым авторлар, иҗат коллективлары һәм төркемнәре катнаша.

5.2. Конкурска гариза бирүчеләр – Конкурс турында нигезләмәнең 6.2. пункты нигезендә документлар тапшырган массакүләм мәгълүмат чаралары (законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) редакцияләре (алга таба – ММЧ редакцияләре), аерым авторлар, авторлар коллективлары.

5.3. Конкурста катнашучылар – тапшырылган эшләре Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән ММЧ редакцияләре (законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән), аерым авторлар, иҗат коллективлары һәм төркемнәре.

5.4. Гариза бирүчеләр Конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә бәян ителгән тәртиптә һәм күрсәтелгән шартларны, таләпләрне үтәп документлар әзерләргә һәм тапшырырга тиеш.

5.5. Конкурска җибәрелгән эшләр ике яки аннан күбрәк затлар тарафыннан башкарылган булырга мөмкин.

5.6. Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык эшләрне тәкъдим иткән катнашучыларга йөкләнә.

5.7. Гариза бирүче Конкурсның бер номинациясендә катнашу өчен бер генә гариза бирә ала.

5.8. Конкурска гариза бирүче берничә номинация буенча документлар тапшыра ала, бу очракта жюри тарафыннан карала торган документлар һәрбер номинация буенча аерым әзерләнергә тиеш.

## 6. Конкурсны үткәрү шартлары

6.1. Конкурска 2018 елның 10 ноябреннән 2019 елның 20 октябренә кадәрге чорда массакүләм мәгълүмат чараларында дөнья күргән эшләр кабул ителә.

Агентлык Конкурска түбәндәге документларны кабул итә:

- катнашу өчен Анкета-гариза (1 нче кушымта);
- түбәндәге конкурс эшләре (кимендә 3 һәм иң күбе 10 эштән торган эшләр циклы):

• MP4 форматындагы CD яисә DVD дискларда (флешкартада) телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, видеосюжетлар циклы). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә редакция мөһере һәм җитәкче имзасы белән (юридик затлар өчен) йә автор имзасы белән (физик затлар өчен) таныкланган булырга тиеш;

• басма массакүләм мәгълүмат чараларындагы язмалар (язмалар сериясе, махсус чыгарылышлар), төп нөсхә яки күчермә нөсхә рәвешендә/сканер аша чыгарылган вариантта. Язмалар редакция мөһере һәм җитәкче имзасы белән (юридик затлар өчен) йә автор имзасы белән (физик затлар өчен) таныкланган булырга тиеш;

• Интернет челтәрендәге язмалар, алар, язмага актив сылтама күрсәтелеп, электрон рәвештә һәм, адреслы сылтама/күчереп алу өчен сылтама күрсәтелеп, кәгазь вариантта булырга, статьяның скриншоты кушып бирелергә тиеш. Язмалар редакция мөһере һәм җитәкче имзасы белән (юридик затлар өчен) йә автор имзасы белән (физик затлар өчен) таныклана;

• MP3 форматындагы CD яисә DVD дискларда (флешкартада) радиоэшләр (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар циклы). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә редакция мөһере һәм җитәкче имзасы белән (юридик затлар өчен) йә автор имзасы белән (физик затлар өчен) таныкланган булырга тиеш.

- Түбәндәге гамәлгә кую документлары (документларны сканер аша чыгарылган PDF-файл форматында тапшыру рөхсәт ителә):

1) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

- юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);
- юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләп кую турында боерык (күчермәсе);
- гамәлгә кую документлары (күчермәләре);
- ММЧ теркәү турында таныклык (күчермәсе) – массакүләм мәгълүмат чаралары өчен;

2) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

- массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык (күчермәсе);
- массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе уставы яисә, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясендә кимендә 10 кеше эшләсә, “Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – ММЧ турында Закон) 20 статьясы нигезендә аны алмаштыра торган шартнамә;

3) физик затлар өчен (авторлар, авторлар коллективлары):

- паспорт яисә аны алмаштыручы документ (күчермәсе);

- персональ белешмәләрне эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга ризалык (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада бирелгән рәвештә);

4) уртак эшләр тапшырган ММЧ өчен:

- конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта акчаны процентлап бүлү турында килешү.

Конкурс эшләре Россия Федерациясе дәүләт телендә, Россия Федерациясе республикалары дәүләт телләрендә, Россия Федерациясе халыкларының башка телләрендә тапшырыла. Россия Федерациясе дәүләт телендә булмаган эшләргә эшнең рус теленә тәрҗемәсе кушып бирелә, тәрҗемә массакүләм мәгълүмат чарасы җитәкчесенең имзасы яки мөһере белән таныклана (булган очракта).

6.2. Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми.

6.3. Документлар **2019 елның 1 ноябренә кадәр** (1 ноябрьне дә кертеп) түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, “Татмедиа” матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы, 6 кат, кадрлар бүлеге, «Коррупциягә журналист карашы» конкурсына» дигән тамга белән. Телефон: 8(843)570-31-10, электрон почта A.Smetanina@tatar.ru.

6.4. Конкурска документлар почта элемтәсе хезмәтләре аша яисә китереп тапшырыла.

6.5. Документлар Агентлыкка кергән көн аларны тапшыру датасы булып санала.

6.6. Анкета-гаризаны һәм конкурс эшен билгеләнгән срокны бозып тапшыру, анкета-гаризаның/конкурс эшенең булмавы, анкета-гаризаның/конкурс эшенең әлеге Нигезләмәгә туры килмәве, сурәтендә яисә тавышында хилафлыклар булган эшләрне тәкъдим итү Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып тора.

6.7. Конкурска кертелмәгән эшләр, җитешсезлекләр бетерелеп, Конкурска документлар тапшыру өчен билгеләнгән срокларда яңадан Конкурска тәкъдим ителергә мөмкин.

6.8. 2019 елның 1 ноябреннән соң алынган эшләр конкурста каралмый.

6.9. Конкурска йомгак 2019 елның декабреннән дә соңга калмыйча конкурс комиссиясе тарафыннан ясала һәм беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

6.10. Конкурсны оештыручылар эшләрне, шул исәптән бүләкләргә лаек булган эшләрне дә киләчәктә файдалануны күздә тотмый, шуңа бәйле рәвештә конкурста катнашучылар эшләрне киләчәктә ничек файдалануны мөстәкыйль хәл итә. Бу авторга иҗади эштән үзе теләгәнчә файдаланырга, аерым алганда, килешү төзерлек зат яисә оешма табу мөмкинлеген бирә.

6.11. Конкурс шартлары буенча, тәкъдим ителгән эшләрне катнашучыларга кире кайтару, конкурста катнашучының эшне кире кайтару турындагы таләбе буенча гына, мондый таләп алынган мизгелдән алып 20 (егерме) календарь көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

6.12. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр документларны алган мизгелдән алып 3 эш көне дәвамында Оештыручы җитәкчесе/җитәкче урынбасары имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы рәсми хат белән хәбәр ителә.

6.13. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) Гариза бирүче/Катнашучы тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

## 7. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

7.1. Конкурс эшләре түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

- теманың ачылуы (0 – 10 балл);
- материалларның актуаль һәм үтемле булуы (материалның мөһим, әһәмиятле булуы, файдаланган ресурсларның көтелгән нәтиҗәләргә ирешүдә ярдәме) (0 – 10 балл);
- авторның (авторларның) һөнәрилек дәрәҗәсе һәм материалларның аналитикасы (0 – 10 балл);
- теманы яктыртуның кабатланмаган булуы, эшнең иҗадилыгы (0 – 10 балл).

7.2. Баллар суммасын призлы урыннар буенча бүлү:

- 1 урын: 32 – 40 балл;
- 2 урын: 23 – 31 балл;
- 3 урын: 15 – 22 балл;

Махсус номинациядә максималь баллар (кимендә 32) җыйган катнашучы җиңүче дип танылa.

7.3. Эшләр циклы циклдагы барлык эшләргә куелган уртача баллардан чыгып бәяләнә.

## 8. Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

8.1.Конкурс комиссиясенең составы Конкурсны оештыручы тарафыннан раслана, 11 әгъзадан тора, аларга рәис, рәис урынбасары һәм әгъзалар керә.

8.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез башкара.

8.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип танылa.

8.4. Конкурс эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары аның тарафыннан билгеләнгән урынбасарына йөкләнә.

8.5. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска тапшырылган эшләрне әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлар нигезендә бәяли. Һәрбер критерий буенча балларның саны 5 баллы шкала (0 – 5 балл) буенча бәйләнә.

8.6. Конкурс эше тиешле номинациягә тапшырылмаган булса, конкурс комиссиясе бу конкурс эшен аңа туры килә торган номинациядә карау хокукына ия.

8.7. Бер номинациягә бер генә гариза тапшырылса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс бу номинациядә үткәрелмәгән дип танылa һәм акчалар билгеләнгән башка җиңүчеләр арасында тигез итеп бүленә.

8.8. Баллар саны тигез булган очракта, номинациядә призлы урын конкурс комиссиясе тарафыннан ике яки берничә катнашучыга бирелә. Тиешле призлы урынга тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында тигез итеп бүленә.

8.9. Берничә массакүләм мәгълүмат чарасы тарафыннан тәкъдим ителгән конкурс эше призлы урын алган очракта, әлеге призлы урынга тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында әлеге Нигезләмәнең 6.2 пункты нигезендә документлар белән бергә тапшырылган килешү нигезендә бүленә.

8.10. Конкурс комиссиясе конкурста җиңүчеләрне Нигезләмәгә таянып билгели.

8.11. Конкурсны оештыручы оештыру-техник эшчәнлекне җайга салу, утырышны әзерләү һәм конкурс комиссиясе документациясен алып бару өчен җаваплы секретарь билгеләп куя.

8.12. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

## 9. Финанс белән тәэмин итү

9.1. Конкурсны үткәрү чараларын финанслау Программада каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

9.2. Гомуми приз фонды 535 000 сум.

9.3. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| **Номинацияләр** | **Бүләкләнүчеләр саны** | **Сумма (сум)** |
|---|---|---|
| 1. Вакытлы матбугат басмаларында коррупциягә каршы иң яхшы язмалар сериясе | 3 | 50 000 |
| | | 40 000 |
| | | 30 000 |
| 2. Коррупциягә каршы иң яхшы телесюжетлар сериясе | 3 | 50 000 |
| | | 40 000 |
| | | 30 000 |
| 3. Коррупциягә каршы иң яхшы радиосюжетлар сериясе | 3 | 50 000 |
| | | 40 000 |
| | | 30 000 |
| 4. Интернет басмаларда коррупциягә каршы иң яхшы язмалар сериясе | 3 | 50 000 |
| | | 40 000 |

| | | |
|---|---|---|
| | | 30 000 |
| 5. Коррупциягә каршы иң яхшы журналист тикшеренүе | 1 | 55 000 |

9.4. Җиңүчеләргә акча конкурска йомгак ясалган һәм беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында аларның Оештыручыга язган хатында күрсәтелгән реквизитлар буенча исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

## 10. Аерым шартлар

10.1. Оештыручы түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;
- эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен (РФ ГК 1058 ст.) үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Агентлыкның рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) “Яңалыклар” бүлегендә һәм Министрлыкның рәсми сайтында (http://mvd.tatarstan.ru) “Яңалыклар” бүлегендә тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

10.2. Конкурсның максатларын һәм бурычларын үзгәртүдән тыш, калган барлык шартларына үзгәрешләр кертергә мөмкин.

2019 елда коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” республика конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

2019 елда коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” республика конкурсында катнашу өчен
АНКЕТА-ГАРИЗА

**Гариза бирүче (ММЧ исеме)**

____________________________________________________________

**ММЧ җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме**

____________________________________________________________

**Элемтә өчен телефон**

____________________________________________________________

**Материалның чыгу датасы**

____________________________________________________________

**Номинация**

____________________________________________________________

**Конкурска җибәрелгән эшнең исеме**

____________________________________________________________

**Кыскача эчтәлеге**

____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________

_____________________________________________________________________
_______________________________

**Адрес** _____________________________________________________________________
__

**Телефон/факс** _____________________________________________________________________
__

**e-mail** _____________________________________________________________________
__

**2019 елда коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” республика конкурсына** җибәрелгән конкурс эшләренең _________ (оешма исеме) милке булуын раслыйбыз. Конкурста катнашу авторлык хокукын яисә өченче затларның нинди дә булса башка хокукларын бозмый. Конкурска җибәрелгән эшләрдән файдалана алу мөмкинлегенә карата өченче затлардан хокукый дәгъвалар кергән очракта, аларны _________ (оешма исеме) белдерергә кирәк.

**Гариза биргән ММЧ җитәкчесенең/ физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча)**_______________________________________

**(гариза биргән ММЧ җитәкчесенең, физик затның мөһер белән таныкланган (булган очракта) имзасы**

2019 елда коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” республика конкурсы үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,_______________________________________________________________
___, яшәү адресым_______________________________________________
______________________________________________________________________
__, шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)______________________
______________________________________________________________________
______________________________________, “Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420097, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) **2019 елда коррупцияне профилактикалау һәм аңа каршы көрәшү мәсьәләләрен Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга багышланган “Коррупциягә журналист карашы” республика конкурсынд**а катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.
Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге: | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында |

| | |
|---|---|
| | ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

_____________________________________________________________/_______________

(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. һәм имзасы)

______________

(Дата)